КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 август г.Казань № 832

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 29 март, 236 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 29 март, 236 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 20 сентябрь, 852 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемдә «авырулар» сүзеннән соң «һәм Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруга дәүләт медицина оешмаларына субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе» сүзләрен өстәргә;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибе;

Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруга дәүләт медицина оешмаларына субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе.»;

әлеге карар белән расланган Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы акчаны җибәрә:

«Республика клиник туберкулезга каршы диспансер» сәламәтлек саклау дәүләт автоном учреждениесенә – Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларында туберкулез микобактериясен ачыклау, аның сизгерлеген билгеләү һәм туберкулез кузгатучының күпсанлы дару тотрыклылыгы белән белән авыручы затларны дәвалау мониторингы өчен федераль бюджеттан субсидияләр исәбеннән сатып алына торган диагностика чаралары исемлеген раслау турында» 2019 елның 25 мартындагы 157н номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектларында туберкулез микобактериясен ачыклау, аның сизгерлеген билгеләү һәм туберкулез кузгатучының күпсанлы дару тотрыклылыгы белән белән авыручы затларны дәвалау мониторингы өчен федераль бюджеттан субсидияләр исәбеннән сатып алына торган диагностика чаралары исемлеге нигезендә туберкулез микобактериясен ачыклау, аның сизгерлеген билгеләү һәм туберкулез кузгатучының күпсанлы дару тотрыклылыгы белән белән авыручы затларны дәвалау мониторингы өчен диагностик чаралар, шулай ук Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Туберкулез белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 елның 15 ноябрендәге 932н номерлы боерыгы белән расланган туберкулез белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтү тәртибендә каралган җиһазлар стандартлары нигезендә медицина эшләнмәләре сатып алуга;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИДны һәм йогышлы авыруларны профилактикалау һәм аларга каршы көрәш буенча республика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә:

кеше иммунодефициты вируслары йоктырган затларны дәвалауны ачыклау һәм мониторинглау өчен диагностик чаралар сатып алуга, шул исәптән В һәм (яисә) С гепатитлары вируслары белән бергә, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган исемлек нигезендә;

ВИЧ-инфекция һәм В һәм С гепатитларын профилактикалау, шул исәптән әлеге чараларны гамәлгә ашыруга социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларны җәлеп итеп.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Акчаны тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгында ачылган шәхси счет аша башкарыла.»;

7 – 11 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

әлеге карарга Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруга дәүләт медицина оешмаларына субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен өстәргә (карарга теркәлгән).

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин